Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге составына керүче Тукай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

КАРАР

2023 елның 21 нче ноябере № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге составына керә торган торак пунктларда гражданнар җыеннарын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 4 октябрендәге 122 номерлы карарына таянып, 2023 елның 21 ноябре 10.00 сәг. узган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнар җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде. "2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Тукай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә һәм үзара салымның алынган акчаларын түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. юлларны кардан чистарту.» сез ризамы дигән сорауга.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 9 граждан кертелде,
җыенда һәм тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 5
Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"Әйе" 5 граждан тавыш бирде;
"Юк" 0 граждан тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Песәй авыл җирлегенең Тукай авылында гражданнар җыенын таныrга Менделеевск муниципаль районы җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. " 2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Песәй авылы җирлегенең Тукай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ

булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, карамагында балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия армиясенә хәрби хезмәткә чакырылганнардан 500 сум күләмендә билгеләргә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итәргә һәм үзара салымның алынган акчаларын Тукай авылында түбәндәге эшләрне үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:
1. юлларны кардан чистарту;" дигән сорауны таныйрга.

3. Әлеге карарны Песәй авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendelevsk.tatar.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы В.И. Мөхәммәтгалиев